КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 июнь г.Казань № 696

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлар эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1188 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлар эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлар эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1188 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 июль, 589 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлар эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның унҗиденче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә, «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүматны ачу стандартларын раслау турында» 2016 ел, 21 июнь, 564 нче сүзләрен «Каты коммуналь

калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүматны ачу стандартлары турында» 2023 ел, 26 гыйнвар, 109 нчы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пунктындагы бишенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин